**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

«30» сентябрь, 2025 ел　　　　№ 712

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру»муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында «22.06.2015 ел, № 1000 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына (07.08.2025 ел, № 585-п үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына кушымтада «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын финанслау 1 бурычны өстәргә. 1.1 пункты нигезендә районда коррупциягә каршы көрәш инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе　　　　И.Р. Дәүләтханов

Кушымта

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1. | Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын эшләү һәм районның гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нигезендә үзгәрешләр кертү (кирәк булганда гамәлгә ашырыла) | ПМР Советы (килешү буенча), ПМР БК, ОМС (килешү буенча) | 2024-2028 | Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә районның җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары өлеше, алар федераль һәм республика законнарына туры килерелде | процентов | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |